КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 сентябрь г.Казань № 837

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 октябрь, 741 нче; 2016 ел, 20 февраль, 104 нче; 2016 ел, 26 май, 354 нче; 2016 ел, 9 ноябрь, 832 нче; 2017 ел, 26 май, 311 нче; 2018 ел, 26 март, 174 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 763 нче; 2019 ел, 17 июнь, 495 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлында «58,2783» һәм «8,7141» саннарын шул ук эзлеклелектә «58,4783» һәм «8,9141» саннарына алыштырырга;

Программаның III бүлегендә:

беренче абзацта «58,2783» саннарын «58,4783» саннарына алыштырырга;

таблицаның «2019» дигән юлында «8,7141» саннарын «8,9141» саннарына алыштырырга;

Программага теркәлгән кушымтада:

3.1 нче пунктның 18 графасында «0,997» саннарын «1,197» саннарына алыштырырга;

4.2 нче пунктның 10 – 13 графаларында «4» санын «6» санына алыштырырга;

4.7 нче пунктта:

10 графада «280» саннарын «800» саннарына алыштырырга;

11 графада «300» саннарын «900» саннарына алыштырырга;

12 һәм 13 графаларда «300» саннарын «1000» саннарына алыштырырга;

5.12.1 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

7.4 нче пунктның 10 – 13 графаларында «4» санын «12» саннарына алыштырырга;

7.5 нче пунктның 10 – 13 графаларында «4» санын «10» саннарына алыштырырга;

10.1 нче пунктның 10 – 13 графаларында «1» санын «3» санына алыштырырга;

«Программа буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән барлыгы» юлында «58,2783» саннарын «58,4783» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин